| | |
|---|---|
| **Исполнительный комитет Новоишлинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Башкарма комитеты** |

422475, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с.Новые Ишли,
ул.Советская, 24 тел.(84375)30-6-24,факс 30-6-25 Nish.Drz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 нче елның 7 нче феврале № 4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авылы җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 ел, №59-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 12.05.2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Яңа Ишле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Ишле авыл җирлеге
Советының 07.02.2020 елның
№4 карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авылы җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе турында

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, электрон документ формасында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган интернет-кабул итү юлы белән, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ел саен башкарыла.

5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча башкарма комитет сәркатибе хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

7.Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8.Башкарма комитет секретаре ел саен аналитик белешмәне Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.